**СОВЕТ ИСКЕ-КАЗАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422730, Республика Татарстан, Высокогорский район, с.Куркачи, ул. Клубная, 4

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ-КАЗАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422730, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Коркачык авылы., Клуб ур., 4

Тел./факс 8(84365) 70-7-00, e-mail:Ikaz.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**18 июль, 2022 ел** **№ 48**

**«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Иске-Казан авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карар проектын гамәлдән чыгару хакында**

Федераль һәм региональ законнардагы үзгәрешләргә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Иске-Казан авыл җирлеге Советының 2019 елның 13 декабрендәге 179 номерлы карары белән кабул ителгән «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Иске-Казан авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы проектын әзерләү максатларында (Советның 07.08.2020 № 192, 18.01.2021 N15 карарлары редакциясендә), әлеге үзгәрешләрне исәпкә алып, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28, 44 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7, 20 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Иске-Казан авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Иске-Казан авыл җирлеге Советының 2021 елның 08 октябрендэ 33 номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Иске-Казан авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карар проекты хакында» карарын гамәлдән чыгарырга.

2. Иске-Казан авыл җирлеге Советының 2021 елның 08 октябрь 33 номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Иске-Казан авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карар проекты хакында» карары нигезендә 2021 елның 28 октябрь 10 сәгатьтә түбәндәге адрес буенча: Коркачык авылы, Клуб урамында үткәрелгән гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен гамәлдән чыгарырга.

3. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Иске-Казан авыл җирлеге Советының 2019 елның 13 декабрендәге 179 номерлы карары белән кабул ителгән ««Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Иске-Казан авыл

җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» (Советның 07.08.2020 № 192, 18.01.2021 N15 карарлары редакциясендә) проектын, федераль һәм региональ законнардагы соңгы үзгәрешләрне исәпкә алып эшләргә.

4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә), шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы Г.Р.Закирова